**Инспекциядә «Хезмәткәрнең үз-үзен коррупциягә каршы тоту стандарты» темасы буенча семинар узды**

2018 елның 22 июнендә ТР Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе киңәшмәләр залында «Хезмәткәрнең үз-үзен коррупциягә каршы тоту стандарты» темасы буенча видеоконференция режимында семинар узды.



Киңәшмә кысаларында хокук идарәсенең юридик бүлеге башлыгы Лилия Булатова һәм коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы зат Алсу Игнатьева доклад белән чыгыш ясады.



Тулырак мәгълүмат  ТР ДТКИ рәсми сайтындагы «Коррупциягә каршы көрәш. Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча докладлар, боерыклар, күзәтүләр, статистик һәм бүтән төрле мәгълүматлар» бүлегендә урнаштырылды (http://gsn.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_1099039.pdf).




ТР ДТКИ матбугат хезмәте, 22.06.2018 г.